**Татарстан РеспубликасыЗәймуниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Бәләкәй Пәлчекәү торак пунктында гражданнар җыены карары**

**11.11.2022** **№1**

«РоссияФедерациясендәҗирлеүзидарәоештыруныңгомумипринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлыФедеральзаконның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәтурында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Бәләкәй Пәлчекәү торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Бәләкәй Пәлчекәү торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
- беседка сатып алу.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Шепкә
авыл җирлеге башлыгы ____________ Камалиева Л.М.